
# Казан шәһәренең истәлекле урыннары

# ТЕКСТНЫ УКЫГЫЗ

- Казан – борынгы шәһәр. Ул Иделнең сул як ярында урнашкан.
- Казанның үзәгендә тарихи һәйкәл – Кремль балкып тора. Казан Кремле турында 16 гасырда ук тарихчылар сокланып язганнар. Аның эчендә таштан эшләнгән ха сарайлары һәм мәчетләр булган. Иң гүзәл архитектура һәйкәле – Сөембикә манарасы.



Башкалабызда берсеннән-берсе матур биналар, урамнар, истәлекле урыннар шактый күп, Алар арасында Милли музей, Сынлы сәнгать музее, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры һәм башкалар. Казан – фән патшалыгы. Шәһәребезнең горурлыгы – университет. Аңа 1804нче елда нигез салынган. Хәзерге университет ул – заманча җиһазландырылган аудиторияләр, лабораторияләр, спорт комплексы, бай фондлы китапханә.

- Казан – танылган мәдәни үзәк.Бүгенге көндә шәһәребездә М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театры, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, В. Качалов исемендәге Зур рус драма академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театры, Яшь тамашачы театры, Курчак театрлары эшләп килә.
- Бүгенге Казан зур, матур, мәһабәт.

# Дөрес тәрҗемәне тап

| | |
|---|---|
| Казань – древний город. | Казанда бер миллионнан артык кеше яши. |
| В Казани проживает более одного миллиона человек. | Казан Иделнең сул як ярында урнашкан. |
| В центральной части города расположен Казанский Кремль. | Казан – борынгы шәһәр. |
| Казань – один из крупных центрв науки и культуры. | Шәһәрнең үзәгендә Казан Кремле урнашкан. |
| Город расположен на левом берегу Волги. | Казан – зур мәдәни һәм фәнни үзәкләрнең берсе. |
| Жители города гордятся своей столицей. | Шәһәр халкы үзенең башкаласы белән горурлана. |

# Сорауларга җавап бирегез

- 1. Казан кайда урнашкан?
- 2. Казанда нинди тарихи урыннар бар?
- 3. Сөембикә манарасы турында нәрсәләр беләсез?
- 4. Казанда нинди югары уку йортлары бар?
- 5. Казан Дәүләт Университеты турында нәрсәләр беләсез?
- 6. Башкалада нинди театрлар эшли?
- 7. Сез кайсы театрларда булдыгыз?
- 8. Казанның тагын нинди истәлекле урыннарын беләсез?

# Җөмләләрне тиешле тәртиптә языгыз

- Бу урамда 14 гасыр ахыры-20 гасыр башында төзелгән биналар, сәүдә йортлары, төрле кибетләр урнашкан. Революциягә кадәр бу урам – Воскресенская, соңрак Ленин исемен йөрткән. Казан Кремле белән университетның төп бинасын Кремль урамы тоташтыра. Шулар арасында Милли музей, Нотариаль контора, шәһәр хакимияте бинасы.

# Җөмләләрне дәвам итегез.

- Татарстанның иң зур шәһәрләре –
- Татарстан аша ага торган иң зур елгалар –
- Казанда урнашкан иң зур музейлар –
- Казанда эшли торган театрлардан –